| | |
|---|---|
| ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 ел, 20 март** **№ 1**

«Петровский Завод авыл җирлеге Кук-Тау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Кук-Тау торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Кук-Тау торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Петровский Завод Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1.2024 елның 30 мартында 09.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Кук-Тау торак пункты, Аркылы урамы, 2а йорт адресы буенча урнашкан Петровский Завод авылы клубы бинасында «Петровский Завод авыл җирлеге Кук-Тау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Кук-Тау торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Петровский Завод авыл җирлеге Кук-Тау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Кук-Тау торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1) гомуми автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге файдалану:

-Кук-Тау торак пунктында Беларус-82,1 тракторын тоту (водитель хезмәтләренә түләү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
-авыл эчендәге юлны ремонтлау (асфальт белән капланган юлны чокырлы урыннарын ремонтлау, сатып алу, ташу, асфальт валчыклар салу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) Кук-Тау торак пунктының Яшел урамына;
2) урам яктырту җайланмасы:
- Кук-Тау торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
3) Кук-Тау торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү:
- зират территориясенә койма тоту өчен материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
4) Кук-Тау торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын кранын урнаштыру);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районының
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы /Р.Р.Нуртдинов/